

# МАСТЕР КЛАСС

**Татарстан Республикасы**
**Яшел Үзән муниципаль районы**
**гомуми белем бирү учреждениясе**
**«Карпов В.В. исемендәге лицей»**

**I квалификацион категорияле укытучы**
**Зарипова Нурзия Нургали кызының эше**

Балаларыгызны үзегезнең заманыгыздан башка заман өчен укытыгыз,чөнки алар сезнең заманыгыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр.

(Р.Фәхретдин)



# Тема

## ФДББС шартларында заманча дәресләр.



# Кредо:Бала тәрбиясе-байлыктан әһәмиятле.

Максат :

Туган телне (татар телен) уку-укытуда заманча актив методлар белән таныштыру.

Уку-укытуда актив методлар булсын өчен :

1)Укытучының укучыга мөнәсәбәте “өстән аска” караган кебек булырга тиеш түгел,ә, бәлки, тигез дәрәҗәдә булсын.

2)Әзер мәгълүматны ,белемне бирү генә җитми Ул белемнәрне укучылар үзләре таба белергә өйрәнсеннәр.Иҗади биремнәр тәкъдим итик.

3)Уку-укытуда реаль булган проблемалар укытучыны креатив уйларга этәрә.

Татар теле һәм әдәбиятын укыту максатлары берничә юнәлешне үз эченә ала:белем бирү, танып белү,үстерү,тәрбияви.

Белгәнебезчә,Федераль дәүләт белем бирү

стандартлары шәхескә кагылышлы нәтиҗәләрне алгы планга куя.Укытучы алдында ничек итеп төрле яктан камил , иҗади үсешкә сәләтле укучыны тәрбияләргә дигән сорау туа?



Дәресләр тагын да кызыклырак булсын дисәк, туган (татар) теле укытучыларының методик компетентлыгын үстерергә кирәк.

- Нәрсәдән башларга мөмкин?
- Оештыру.(мәкаль,әйтем, афоризм,эпиграф)
- Дәреснең максатларын билгеләү,уку эшчәнлегенә мотивацияләү.Дәреснең темасы сорау булып яңгырарга мөмкин.Бу вакытта сорауга җавап бирү юлларын күрсәтәбез.
- Төшенчә өстендә эш.
- Уйлап бетер.Кыска диалог.

**Укучының бу биремне эшләгәндә күзәтелә торган типик хаталары нинди?**



# Белемнәрне актуальләштерү.

Интеллектуаль разминка.(нәрсә артык?нәрсә төшеп калган?логик чылбыр)Шпаргалкалар конкурсы.(шартлы билгеләр,схема,рәсем,ук) Хатаны тап.(хата җибәрә һәм укучы таба)

Идеяләр,исемнәр,төшенчәләр,исемлеге.

Ассоциатив рәт.



| **Яңа белемнәрне беренчел үзләштерү** | **Яңа белемнәрне беренчел ныгыту** | **Белем һәм күнекмәләрне мөстәкыйль куллану** |
|---|---|---|
| Төп терминнар | Әйе-Юк | Мини- проект |
| Текстка сораулар | Кластер | Мини- тикшеренү |
| Интернет -ресурслар | Интеллект карта | Иллюстратив материал белән эшләү |
| Яхшы-начар | Дидактик карточкалар | Реставрацияләү |

Текстка сораулар билгеле критерийларга таянып төзелә.

- Ни өчен?
- Ни дәлиләргә?
- Нәрсә белән аңлатырга?
- Нинди очракта?Ничек итеп?


- Жокей һәм ат.(сораулар һәм җавапларны бер-берсенә туры китереп табарга тиеш)
- Сорау бирелә.1 генә җавап дөрес. Шуны сайлыйлар.
- Блиц опрос 10 сорау. Тиз генә җавап бирү.
- Рефлексиядә укучы үзен баскычка куя.

(Мин бүген башкаларның фикерен тыңладым.Авырлык сизмәдем.Мин идеяләр тәкъдим иттем . Авырлыкны җиңә алдым)

# Рефлексия алымы

Рефлексиядә укучы үзен баскычка куя:

- -Мин бүген башкаларның фикерен тыңладым.
- -Авырлык сизмәдем.
- -Мин идеяләр тәкъдим иттем .
- -Авырлыкны җиңә алдым.



# Кайбер башка алымнар.

- “**Блум акчәчәге** ”Акчәчәк 6 таждан тора.Аларның һәрберсе билгеле бер тип сорауны үз эченә ала.Шулай итеп 6 таҗ-6 сорау
- 1.Гади сорау.Бу сорауга җавап биргәндә ниндидер фактларны ,мәгълүматларны искә төшерергә кирәк.**Кем?Кайчан? Кайда?**
- 2.Ачыклык кертә торган сораулар.Мондый сораулар:Әгәр дә мин сине дөрес аңласам,.....**Димәк, синеңчә**...Фикерне исбатлый белергә өйрәтү.
- 3.Аңлата торган сораулар.**Ни өчен**? Соравы белән башлана һәм сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтен аңлата
- 4.Иҗади сораулар.Фантазиягә нигезләнеп җавап бирелә торган сораулар “**Әгәр...”** сүзе белән башланырга мөмкин.
- 5.Практик сораулар Әсәрдәге сюжетны укучыларның тормышына күчерү **Герой урынында үзегезне ничек тотар идегез?**
- 6.Бәя бирүче сораулар Бу сораулар теге яки бу вакыйгага бәя бі критерияләрен билгеләү максатыннан бирелә.

# “Инсерт” алымы

V(галочка)тамгасын укучы тексттагы мәгълүмат белән күптәннән таныш булган очракта куя. Ул моны белә.

+(плюс)тамгасын укучы узенә таныш  булмаган яңа мәгълүматны очратканда куеп бара.

-(минус) тамгасын укучы текстта очраган мәгълүматның үзе моңарчы беләм дип йөргән фикер белән туры килмәвен күргәч куя.

?(сорау) тамгасы белән укучы таныш булмаган мәгълүматны билгели. Ул моны белергә теләвен күрсәтә.

# «Вакыт аралыгындагы фикерләр”

- Күзаллау белән бәйле рефлексия алымы.
- Укытучы дәрес темасы белән бәйләнештәге төп ,терәк сүзне атый. Укучылар 1 минут дәвамында әлеге сүз белән туган күзаллауларын ,кичерешләрен, фикерләрен язалар. Вакыт тәмамлангач, укучылар үз язмаларын укыйлар.



# “Эйдос –конспект “алымы

- *Э-К* әдәби әсәрнең темасына яки әдәби образларын хис-кичерешләр,сәнгать  аркылы аңлату.
- Э-К үзендә терәк конспект һәм иллюстрацияләрне берләштерә. Э-К төзегәндә ,баш миенең ике ягы да эшкә җигелә,логик фикер йөртүе дә һәм образлы фикер йөртүе дә.
- Э-К укылган әсәрнең иҗади проекты булып тора.
- 3 төрен аерып чыгаралар:
- Төсләр нигезендә ясалган.
- График сызулар нигезендә.
- Сәнгать аркылы аңлатылган.



# Проектлар алымы

Укытучының иң төп бурычы-туган телендә уйларга ,фикер йөртергә сәләтле булган укучы тәрбияләү.Үз халкының гореф-гадәтләрен,тарихын,мәдәниятен белсә генә укучы шәхес итеп формалаша, минемчә.

Бала үз телен ,әдәбиятын белергә тиеш.Без укучылар белән төрле фәнни конференцияләрдә катнашабаз.Бу эш алымының үз тәртибе ,кагыйдәләре бар:

1.Укытучы ,укучысын күз алдына китереп, нинди конференциядә катнашасын сайлый.

2. Укучыга кызыклы тема тәкъдим итә.Шуннан соң эзләнү эше башлана.Максат һәм бурычлар билгеләнә.

3.Укучының сыйныф җитәкчесенә дә конференциянең кайчан һәм кайда булачагын хәбәр итә.

4. Укытучы, район мәктәбенә яки шәһәргә барасы булса ,укучының әти –әнисе белән дә сөйләшеп,ризалык ала.Бар җаваплылыкны үз өстенә алып , юлга чыгып китә.

Ни өчен кирәк соң бу эш?Беренчедән,балалар зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясау күнекмәләренә өйрәнәләр.Икенчедән,интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерәләр.

Каюм Насыйри исемендәге
15 нче Халык ара фәнни-
тикшеренү яшьләр
конференциясе
Тема:Бишек җырлары
Мөхәммәтҗанова Гөлия
9 А кл.



«Карпов укулары» Фәнни- гамәли конференциясе

Тема:”Осиновода яңа урамнар”

Безус Артем 8 Б класс



**Шәҗәрәләр –нәсел агачы.**
5 нче төбәкара фәнни –
гамли конференция.
Катнашучы: Идиятуллин
Салават, 9 В кл.



«Путешествие к истокам»

Зарипова Эльвира

8Б класс



- Муниципаль конкурс

«Әбиемнең сандыгы»

Дәминова Зилия ,3Г кл



# Рефлексия

- Бүгенге мәктәп югары белемле, компетентлы,инновацион үсешкә бәйле белем бирү системасының иң катлаулы мәсьәләләрен чишәргә әзер булган укытучыларга мохтаҗ.



# Игътибарыгыз өчен рәхмәт.